ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.08.2019 г. № 500

Түбән Кама шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан Түбән Кама муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле рәвештә кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен, Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына, Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле рәвештә кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен, башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 ноябрендәге 887 номерлы карары үтәлеше өчен, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан Түбән Кама муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле рәвештә кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен, Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирүнең теркәлгән тәртибен расларга (1-нче кушымта).

2. Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы кулланучылар кооперациясе оешмаларын сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссияне расларга (2-нче кушымта).

3. Бюджет акчаларын алучы буларак, баш бүлүче функцияләрен Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

4. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетының сәүдә һәм кулланучыларга хезмәт күрсәтү бүлегенә тәэмин итәргә:

- Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында гаризалар кабул итү турында хәбәр урнаштыру;

- субсидия алучыларны сайлап алу.

5. «Түбән Кама муниципаль районының бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениясе әлеге карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары белән расланган юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрнең 4 пунктындагы «д» пунктчасында каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы килешүнең типлаштырылган формасын расларга.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (инвестицияләр, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм АСИҮТ буенча) Р.И.Беляевка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 22-нче август
500-нче номерлы карары белән расланган
1-нче кушымта

Түбән Кама шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан Түбән Кама муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле рәвештә кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен, Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына, Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле рәвештә кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен, башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 ноябрендәге 887 номерлы карары, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары, «Россия Федерациясендә кулланучылар кооперациясе (кулланучылар җәмгыятьләре, аларның берлекләре) турында» 1992 елның 19 июнендәге 3085-1 номерлы (2013 елның 2 июлендәге редакциядә) Россия Федерациясе Законы нигезендә кабул ителгән.

2. Субсидия Түбән Кама шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан Түбән Кама муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле рәвештә кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарын каплау максатларында бирелә.

3. Әлеге Тәртип максатларында кулланучылар кооперациясе оешмалары дигәндә, кулланучылар җәмгыяте - гражданнарның һәм (яки) юридик затларның, кагыйдә буларак, территориаль билге буенча, аның әгъзаларының сәүдә, әзерләү, җитештерү һәм башка эшчәнлек өчен милек пай кертемнәрен берләштерү юлы белән әгъзалык нигезендә, аның әгъзаларының матди һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында оештырылган гражданнарның ирекле берләшмәсе аңлашыла.

4. Әлеге Тәртип максатлары өчен аз халыклы авыл пункты астында яшәү урыны буенча теркәлгән, 600 дән кимрәк кеше яшәгән аз халыклы авыл пункты аңлашыла.

5. Субсидия түбәндәге критерийларга җавап бирә торган кулланучылар кооперациясе оешмаларына бирелә:

- әлеге Тәртип таләпләренә туры китереп документлар тапшыру;
- субсидия алучының әлеге Тәртип таләпләренә туры килүе.

6. Түбән Кама шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан Түбән Кама муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле тотылган чыгымнар буенча субсидия күләме Түбән Кама муниципаль районы бюджетында бу максатка каралган акчадан күбрәк булмаган тотылган чыгымнар суммасыннан чыгып билгеләнә.

7. Түбән Кама шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан Түбән Кама муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәк-ле товарлар китерүгә бәйле чыгымнарны каплау Түбән Кама муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 2. Субсидия бирү шартлары һәм сроклары

1. Субсидия алучы субсидияләр бирү һәм субсидия алуга Килешү (алга таба – килешү) төзү өчен Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты сәүдә һәм кулланучылар бүлегенә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре, Мәктәп бульвары ур., 2А йорт, түбәндәге документларны тапшыра:

-Түбән Кама шәһәреннән 11 чакрым ераграк урнашкан Түбән Кама муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче кирәкле товарлар китерүгә бәйле чыгымнар турында белешмәләр (мәгълүмат) булган исәп-хисап белән билгеләнгән формада (Тәртипкә 1 нче кушымта) субсидия бирү өчен гариза;

- кулланучылар җәмгыяте төзү турындагы карар күчермәсе;
- оештыру документлары күчермәләре;
- юридик затның дәүләт теркәве турындагы таныклык күчермәсе;
- дәгъвачы исеменнән гамәлләр башкаруга затның вәкаләтләрен раслый торган документ күчермәсе (әгәр дә дәгъвачы исеменнән вәкил эш йөртсә);
- юридик затларның Бердәм дәүләт реестрына язма кертү турында таныклык күчермәсе;
- Россия Федерациясе территориясендә урнашу урыны буенча салым органында юридик затны исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

2. Субсидия күләмен исәпләү формула буенча башкарыла:

$$С = Р * Н * (100\% + К1) * Ц \ / \ 100,$$

кайда:

С – субсидияләр күләме, сум;

Р –Түбән Кама шәһәреннән 11 чакрым ераграк урнашкан Түбән Кама муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче кирәкле товарлар китерү өчен файдаланыла торган транспорт чаралары үткән юл, юл кәгазьләре мәгълүматлары буенча, километр;

Н – Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль транспортында ягулык һәм майлау материалларын тоту нормалары» методик тәкъдимнәрен гамәлгә кертү турында» 2008 елның 14 мартындагы АМ-23-р номерлы боерыгы нигезендә ягулык тотуның база нормасы, 100 километрга литр;

К1 – Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль транспортында ягулык һәм майлау материалларын тоту нормалары» методик тәкъдимнәрен гамәлгә кертү турында» 2008 елның 14 мартындагы АМ-23-р номерлы боерыгы нигезендә елның кышкы чорында автотранспорт эше өчен ягулыкның база нормасын арттыру коэффициенты, процентлар;

Ц – Товар китерү датасына Түбән Кама муниципаль районында ягулык-майлау материалларына базар бәясе -1 литр өчен сум.

3. Килешү төзү планлаштырыла торган айдан алдагы айның беренче числосына башка бюджетара трансфертларны алучылар туры килергә тиешле таләпләр:

- субсидия алучыларның  Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

- субсидия алучыларның әлеге карар нигезендә субсидияләр бирү планлаштырылган Түбән Кама муниципаль районы бюджетына кире кайтару буенча кичектерелгән бурычлары, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләр, бюджет инвестицияләре, һәм әлеге карар нигезендә Түбән Кама муниципаль районы бюджеты алдында срогы чыккан башка бурыч булмаска тиеш;

- субсидия алучылар - юридик затлар үзгәртеп кору, бетү, банкротлык процессында булырга тиеш түгел;

- субсидия алучылар чит ил юридик затлары, шулай ук барлыгы 50 проценттан арткан мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналары) үткәргәндә, салым салуның ташламалы салым режимын тәкъдим итүче һәм (яки) мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган  Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән  дәүләт яки территория теркәлү урыны булган чит ил юридик затларының катнашу өлеше  устав (җыелма) капиталына  кергән Россия юридик затлары булырга тиеш түгел;

- субсидия алучылар әлеге карар нигезендә, башка норматив хокукый актлар яки муниципаль хокукый актлар нигезендә әлеге Тәртипнең 1 бүлегенең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидия бирү планлаштырыла торган Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан акча алырга тиеш түгел.

4. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә һәм кулланучылар хезмәте күрсәтү бүлеге теркәлгәннән соң 15 эш көне дәвамында субсидия алу хокукына дәгъва кылучы кулланучылар кооперациясе оешмаларын (алга таба – Комиссия) сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссияне чакыра, ул кергән гаризаларны карый һәм субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында беркетмә рәвешендә карар чыгара.

Комиссия тарафыннан карар кабул ителгәннән соң 1 эш көне дәвамында Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә һәм кулланучылар хезмәтләре бүлеге субсидия алучыга кабул ителгән карар турында хәбәр итә һәм субсидия алучыга килешү проектын җибәрә.

Субсидия бирү турында Карар кабул иткәндә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә һәм куллану хезмәтләре бүлеге беркетмәне Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтер исәбе һәм хисап бүлегенә җибәрә.

5. Субсидия алучыга субсидия бирү һәм аны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты адресына җибәрү турындагы килешүгә кул кую өчен срок – 2 календарь көн.

6. Субсидия бирү турындагы килешүнең типлаштырылган формасы «Түбән Кама муниципаль районының бюджет һәм финанслар департаменты» МКУ тарафыннан билгеләнә.

7. Субсидия бирү турындагы килешүдә субсидия бирүнең максатлары, шартлары һәм тәртибе; субсидия күләме һәм аны күчерү вакыты; субсидия биргәндә субсидия алучы тарафыннан билгеләнгән шартларны үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе; субсидиядән файдалану турында хисап бирү формасы, сроклары һәм тәртибе, килешү төзелә торган срок; Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Түбән Кама муниципаль районы «Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыру хокукы; якларның җаваплылыгы.

8. Субсидия бирү турындагы килешүгә кертелгән субсидия алучының Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Түбән Кама муниципаль районының «Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан субсидия бирүнең шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерү өчен ризалыгы мәҗбүри шарт булып тора.

9. Субсидия акчалары максатчан характерда һәм башка максатларга да куллана алмый.

10. Субсидия алучы белән Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты арасында субсидия бирү өчен төзелгән килешү (алга таба – Килешү) субсидия бирү өчен нигез булып тора.

11. Субсидия күчерү Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтер исәбе һәм хисап бүлеге тарафыннан субсидия алучының банкта ачылган исәп-хисап счетына, бу максатларга Түбән Кама муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

12. Субсидия алучыга субсидия бирү вакыты: комиссия тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгәннән соң унынчы эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия алучы тарафыннан килешү төзү шарты белән, әлеге Тәртипнең 2 бүлегенең 5 пунктында билгеләнгән срокта, әмма 2019 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча.

13. Субсидия алучы тарафыннан субсидия алу турында хисап хисаптан соң килгән айның 5 нче числосына кадәр квартал саен Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына бирелә.

## 3. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез һәм субсидияне кире кайтару тәртибе

1. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез:

- субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларны тулы күләмдә тапшырмау/тапшыру;

- субсидия алучының әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

- субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

2. 2019 елның 15 декабренә кадәр кулланылмаган субсидия калдыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының территориаль бүлегендә ачылган Башкарма комитетның шәхси счетына күчерү юлы белән, 2019 елның 20 декабренә кадәр Түбән Кама муниципаль районы бюджетына субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

3. Субсидия алучының аны бирү шартларын бозган очракта, субсидияне күчерү бозуларны бетергәнчегә кадәр туктатыла.

4. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты яки бюджет акчаларын максатчан файдалануны тикшереп торырга вәкаләтле органнар субсидияләрне максатсыз куллануны ачыкланган очракта, субсидия алучы, таләп буенча, артык алынган суммаларны Түбән Кама муниципаль районы бюджетына әлеге таләпне алган көннән 5 көн эчендә кире кайтара.

5. Субсидия алучы тарафыннан субсидияне кире кайтару өчен билгеләнгән срокны бозганда, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты әлеге Тәртипнең 3 бүлегенең 4 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң 7 көн эчендә Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә Түбән Кама муниципаль районы бюджетына субсидияне кире кайтару буенча чаралар күрә.

Тәртипкә
1-нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
А.Г.Сәйфетдиновка
_________________________________
(оешма исеме)
Адрес:______________________________
____________________________________
«____»______________2019 ел

Субсидия бирүгә
ГАРИЗА

Сездән Түбән Кама шәһәреннән 11 чакрым ераграк урнашкан Түбән Кама муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче кирәкле товарлар китерүгә бәйле чыгымнарны кайтаруга
__________________________(______________________________________) сум
(суммасы цифрлар белән һәм язмача)
субсидия бирүегезне (күчерүегезне) үтенәм.

Субсидия күләмен исәпләү:
___________________________________________________________________

Теркәлгән документлар:
1.

Җитәкче__________________/______________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)
Баш бухгалтер_________________/______________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

М.У.

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 22-нче август
500-нче номерлы карары белән расланган
2-нче кушымта

Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы кулланучылар кооперациясе оешмаларын сайлап алу буенча комиссия
СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| Әхмәтов Л.Р. | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш һәм проект идарәсе буенча урынбасары, комиссия рәисе; |
| Вафин М.Х. | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә һәм куллану хезмәтләре бүлеге башлыгы, комиссия секретаре. |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| Беляев Р.И. | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инвестицияләр, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм АСИҮТ буенча беренче урынбасары; |
| Нигъмәтҗанов А.Г. | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең авыл хуҗалыгы буенча урынбасары; |
| Логинова С.А. | - | ТР Түбән Кама муниципаль районы Бюджет һәм финанслар департаменты җитәкчесе. |

Татарстан Республикасы
сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары
А.Ш.Хөсәеновка
Түбән Кама муниципаль районы
Уставы нигезендә эш итүче
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
А.Г.Сәйфетдинов йөзендә
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетыннан

Гариза

Сездән Түбән Кама шәһәреннән 11 чакрым ераграк урнашкан Түбән Кама муни-ципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче кирәкле товарлар китерүгә бәйле чыгымнарны кайтаруга ____________________________(______________________________________) сум субсидия бирүегезне үтенәм.

Субсидияләрне түбәндәге реквизитлар буенча күчерүегезне үтенәм:
Алучы:
ИНН
р/с
Банк исеме
Корр. Счет
БИК
ОКТМО
Урнашу адресы:
Фактик урнашу адресы:
Җитәкченең элемтә өчен телефоны:
E-mail:

__________________/А.Г.Сәйфетдинов «____»__________2019 ел
(җитәкче имзасы)